Олыяз авыл җирлеге Советы

КАРАР

18 декабрь № 37

Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 9 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Олыяз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрель 9 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 7 ноябрендәге 29 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 7 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 6 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 6 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы, 2023 елның 30 октябрендәге 32 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Олыяз авыл җирлеге башлыгына классны чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы ________________ Р.Ф.Маликов